ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРЖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерже шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«02» март 2023 ел № 37

Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районы буенча 2023 елның I-II кварталында торак мәйданының 1 квадрат метрының уртача базар бәясен раслау турында

"Бәяләр диапазонын билгеләү турында" 2023 елның 10 февралендәге 35 номерлы "Татарстан Республикасы бәяләүчеләр берлеге" коммерцияле булмаган партнерлыгының хаты, "Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм жирле үзидарә органнарына бәяләү эшчәнлегенә бәйле рәвештә эксперт һәм консультацион ярдәм күрсәтүне гамәлгә ашыруга чыгымнарны финанс белән тәэмин итү (каплау) максатларында коммерцияле булмаган оешмаларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш) Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен раслау турында" 2021 елның 19 ноябрендәге 1104 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, "Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү" дәүләт программасын раслау турында" 03.10.2019 елның 888 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «2020 - 2025 елларга Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасын гамәлгә ашыру кысаларында гражданнарның торак шартларын яхшырту чараларын үткәрүгә социаль түләүләр исәплəү өчен торакның гомуми мәйданының бер квадрат метрының бәясен Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районы территориясендә 2023 елның I-II кварталына 41 000 сум күләмендә расларга.

2. Әлеге карарны “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://www.agryz.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның гамәли көче 01.03.2023 елдан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары К. М. Сотовка йөкләргә.

**Җитәкчесе** **Л.Ф.Нургаянов**